


# Чишмә

52 НЧЕ ТАТАР УРТА ГОМУМ БЕЛЕМ БИРУ МӘКТӘБЕ

№60, ноябрь, 2017






Мәктәбебез директоры -
Кайбышев Сәйфи абый.
Усал кебек күренсә дә,
Усал түгел ул алай.

Гадел һәм гади кеше ул.
Таләпчән дә, тугъры да.
Гомер буе эшләгән ул
Белем бирү юлында.

Директор абыебызга
Алтмыш яшь тулган икән!
Кызык инде, ул да элек
Шук малай булган микән?!

Ю-у-ук, бик житди булгандыр ул,
Рогатка атмагандыр,
Дәфтәрен югалтмагандыр,
Тәрәзә ватмагандыр.

Бик тәртипле булып кына
Укыгандыр мәктәптә.
Гел «бишле»ләр алгандыр ул
«Отличник»тыр, әлбәттә.

Рәхәттер ул аның кебек
Директор булулары!
Һәрчак житди булулары,
Акыллы булулары.

Мин дә зур үсеп житәм дә,
Директор булам әле.
Түр башында ыспай гына
Утырып торам әле.

Барысы да тыңласыннар,
«Бишле»гә укысыннар.
Дәресләрдә шауламыйча,
Тәртипле утырсыннар!

Минме?! Мин, мин иң текә
Директор булачакмын!
Тыңламаган малайларның
Колагын борачакмын.

Ә шулай да, күңелсездер
Гел тәртипле булу да,
Дөрес кенә утыру да,
Гел өйрәтеп тору да.

Директор абыйны кайчак
Кызганып куям үзем.
Бер генә дә шаярмыйча,
Ничек түзә көнозын?!

Әй-лә, рогаткадан атарга
Өйрәтәм әле үзен!!!

## Хөрмәтле Сәйфи Рифхат улы!

Чын күңелдән котлыйбыз без Сезне
Гомер бәйрәмегез житү белән.
Сәламәтлек Сезне ташламасын,
Эшләрегез уңып торсын гелән.

Якты маяк булып әле озак
Житәклэгез безнең мәктәпне.
Сез булганда алга барыр уку,
Мәктәбебез булыр атаклы.

Рәхмәт сезгә барысы-барысы өчен!
Төпле киңәш, сабак бирәсез.
Кирәк чакта шук һәм шаян да сез,
Таләпчән дә була беләсез.

Сезнең исем якты төсләр белән
Уелгандыр безнең күңелгә.
Рәхмәтебез, чиксез хөрмәтебез -
Яшәр һәрчак күңел түрендә.



## Әни!

Әни! Җир йөзендә иң гүзәл, иң газиз сүз. Яшь баланың авызыннан чыга торган иң беренче сүз ул! Һәр әни үз баласын кешеләр белән сөйләшергә, олыларны ихтирам итәргә, тәрбияле, акыллы, тәртипле булырга өйрәтә, һәр әни үз баласын кешелекле булырга өнди. Баласы юлда булса, төннәрен йокысыз үткәрүче, баланы яклаучы, саклаучы да – әни! Ул барлык телләрдә дә бердәй назлы яңгырый. Ана белән бала арасындагы керсез мәхәббәт – табигать бар иткән иң бөек хис ул.

Әни кешенең мәрхәмәтлелеген, шәфкатьлелеген сүз белән генә язып бетереп булмый. Ана йөрәге – иң сизгер йөрәк. Балага булган мәхәббәт хисе беркайчан да сүнми. Баласының язмашына кагылышлы бер генә нәрсәне дә, ана йөрәге ваемсыз үткәрә алмый. Безне, дөньга туганнан алып, әниләрнең күңел һәм кул җылысы озата бара. Аналар сөенечләрен кояш кебек балкып торган нарасыен кулга ала, үчти-үчти диеп түшәмгә чөя, әле сабыеның битеннән, маңгаеннан, тәпи очыннан үбеп ала.

Әни! Нинди матур сүз бу. Кеше үз гомерендә "ана"сүзен ничә тапкыр әйтә микән? Әйткән саен ул сүз яңа мәгнә алып килә. Бу сүз һәрвакыт йөрәкләрдә.

Әниләр безгә авыр вакытларда булыша. Һәрбер адымыбыз белән кызыксынып торалар. Без әниләребезне бик яратабыз, хөрмәт итәбез. Аларның йөзенә кызыллык китермәскә тырышабыз. Аларга булган рәхмәтебезне беркайчан да түләп бетерә алмаячакбыз.

*Хамматова Айгөл, 10 а сыйныфы*

## Әнием – фәрештәм

Фәрештә – безне авырлыклардан, начар, явыз кешеләрдән, ямьсез гамәлләрдән яклаучы һәм саклаучы. Безнең һәрберебезнең үз фәрештәсе бар. Әйе, әйе бар. Ләкин кайберәүләр бу турыда белмиләр генә. Кем соң ул безнең саклаучыбыз, фәрештәбез? Әниләр ул – фәрештәләр.

Дөньяга бала туа. Йомшак куллар аны иркәләп, күкрәгенә кыса. Шушы илаһи мизгелдән һәрбер бала үз фәрештәсе кулларында. Әни, әнием, әнкәй!.. Бала өчен иң якын, матур сүз шушыдыр. Нинди җылы, нинди йомшак бу сүз. “Әнием син минеке, минеке генә бит!” – диеп, үзенең кечкенә куллары белән әнисенең бармакларына тотынган кечкенә генә бала. Әниебезнең йомшак куллары безне иплəп-сөеп кенә тәпи басарга өйрәтә, без беренче адымнарыбызны атлыйбыз, шушы куллар җитәкләп ишегалдына алып чыга, яшел бәбкә үләндә чүпләнеп йөрүче үрдәк бәбкәләре, сары чебешләр, йортны саклаучы маэмай белән таныштыра. Нәни кулларыбыздан тотып, безне балалар бакчасына, аннары белем йорты – мәктәпкә алып бара. Авыр өй эшләрен эшләгәндә булыша. Без бөтен гомеребез буе, кайда гына булсак та, нәрсә генә эшләп йөрсәк тә һәрвакыт әниебезнең сулышын, кул җылысын, күз карашын янәшәдә тоябыз. Әни!.. Никадәр сөю, мәхәббәтне үзендә саклый бу сүз. Әниләр кебек безне беркем дә, беркайчан да ярата алмаячак. Әниләр үз нарасыйларын яклаган кебек безне беркем дә якламаячак һәм сакламаячак.

Әйе, чыннан да безнең һәрберебезнең үз фәрештәсе бар икән. Һәм ул фәрештә “әни” диеп атала. Һәрбер кеше фәрештәсен яратсын. хөрмәт итсен, беркайчан авыр сүз, ямьсез гамәл белән рәнҗетмәсен иде!

*Шәрипова Илвина, 5а сыйныфы*

## Ярый әле әнием бар!

“Тор, тор инде, кызым, бәбкәм, мәктәпкә укырга барасың бар. Соңга каласың бит!” – “Торасы килми, әнием, тагы әз генә ятыйм әле”. Шулчак йомшак иреннәре белән бит очымнан үбә, кочаклап ала. Мин ирексездән елмаям, урынымнан сикереп торам. “Ярый әле, әнием, син бар дөньяда!” диеп әниемнең кочагына ташланам.

Әни – җирдә иң газиз, якын кеше. Ул сине тудырган, көйләп бишектә тирбәткән, синең беренче елмаюыңны, беренче әйткән сүзләреңне ишетеп сөенгән,тәпи атлап китүеңне күреп шатланган.Ул безне туган телебезне яратырга өйрәткән. Без үзебезнең тормышыбызны алардан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Алар – безнең дөньябызның яме, шатлыгы.

Һәркемгә үз әнисе дөньядагы иң кадерле кеше булган кебек, миңа да үз әнием бик кадерле. Барлык балаларныкы кебек, минем дә телем»әннә», «әни» сүзе белән ачылган. Әнием бик сабыр, изге күңелле, ярдәмчел, тыйнак кеше. Әниемнең йомшак куллары, ягымлы тавышы миңа шатлык китерә. Мин әниемә кулымнан килгәнчә булышырга, аны борчымаска тырышам. Әнием миңа дәресләремне эшләргә дә булыша: аңламаган сорауларыма да сабыр гына җавап таба, файдалы киңәшләрен дә бирә.

Мин мәктәптән кайтуга, өйдә тәмле ис таралган була. Әнием инде тәмле-тәмле ризыклар пешереп куярга дә өлгергән! Без аның белән тәмләп чәй эчәбез, серләребез белән уртаклашабыз. Мин ашыга-ашыга мәктәптә көнемнең ничек үтүен, нинди кызык хәлләр булуын сөйлим. Әнием игътибар белән тыңлап утыра. Ял көннәрендә без саф һавада йөрергә яратабыз. Әнием мине һәр кичне назлап йоклата, ә иртән «кызым» диеп сөеп уята. Нинди зур бәхет! Ярый әле, әнием, янәшәмдә син бар! Әнием, мин сине бик яратам!

*Сабирҗанова Сабина, 5а сыйныфы.*

Әниеңә карата мөнәсәбәтең нинди булса, асылың да шундый, рухи дөньяң да, тәрбияң дә шундый дигән сүз.

М. Шәймиев.

## Әни – газиз сүз.

Әни... Ниниди газиз сүз. Әни ул һәркем өчен дә кадерле. Без иң беренче сүзне әни дип эндәшәбез. Әни кеше безне карап үстерә, киендерә, ашата, авыр чакта ярдәм кулы суза.

Һәр үз баласын кешеләр белән сөйләшергә, олыларны ихтирам итәргә кирәк дип тәрбияли. Акыллы, тәртипле булырга өйрәтә. Һәр әни үз баласын кешелекле буларга өнди. Баласы юлда булса, төннәрен йокысыз үткәрүче, баланы яклаучы да ул – әни!

Әнинең нурлы йөзен күреп уяну, аның җылы кочагында иркәләнү –минем өчен зур бәхет. Авыр вакытларда мин аның янына киләм һәм киңәш сорыйм. Әниләр безгә һәрчакта үзенең дөрес киңәшләре белән булыша. Әнисез безнең дөньябыз буш.

Әниләр беркайчан да үз балаларын оныта алмыйлар, ә балаларның кайберләре, кызганычка каршы, оныталар шул. Ана күңеле – балада, бала күңеле – далада, дип юкка гына әйтмиләр шул.

Иң кадерле кешеләребезне беркайчан да онытмагыз, алар безнең тормышыбызның маягы.

FUTURU.RU

*Хәсәншина Зарина 10 а сыйныфы.*

Мәктәп укучылар советы көндәлегеннән ...



12 октябрь көнне Яр Чаллы шәһәренең 52 нче урта гомуми белем бирү мәктәбендә «Бер күрешү – бер гомер» дип исемләнгән әдәби кичә булып узды. Шәһәрнең татар теле һәм әдәбияты укытучылары, мәктәп укучылары каршында ТР Язучылар берлегенең Яр Чаллы оешмасы җитәкчесе Ф.Сафин, шагыйрь Равил Рахмани, Чаллы төбәгендә яшәп иҗат итүче танылган каләм әһелләре Сирень Якупова, Айрат Суфиянов, Әлфия Ситдыйкова, Рәзинә Мөхияр чыгыш ясадылар. Шулай ук яшь каләм әһелләре Лилия Фәттахова, Сөмбел Әхмәтҗанова, Алия Корбановалар да үз шигырьләрен укып ирештерделәр. Кичәне шагыйрь Лилия Гыйбадуллина алып барды.



Очрашу шигырьләр уку һәм җанлы үзара сөйләшү рәвешендә булып, музыкаль чыгышлар белән дә үрелгән иде. Ф.Дәүләтбаев сүзләренә Ф.Сафин иҗат иткән «Хәтер көне» җыры биредә халыкка тәүге тапкыр тәкъдим ителде.

13 нче октябрь көнне мәктәбебездә “Уңыш бәйрәме” уздырылды. Башлангыч сыйныф укучылары ,урта сыйныф укучылары җиләк-җимешләрдән күргәзмә оештырдылар. Бәйрәмдә әти-әниләр,укучылар катнашты.

18.09.-26.10 аралыгында 4-11 нче сыйныф укучылары өчен фәннәрдән мәктәп тур олимпиадалары уздырылды. Анда җиңүче укучыларыбыз шәһәр тур олимпиадаларында катнашачак. Аларның җиңүләрен теләп калабыз.

25 нче октябрь көнне “Татар кызы-18” бәйгесе оештырылды. Кызларның татар халкының йолалары, гореф-гадәтләре, сәнгатьне белүләре сыналды. 1-4 нче сыйныф укучылары өчен бәйге күңелле узды. Җиңүче укучы шәһәр бәйгесенә катнашырга тәкъдим ителде.



Көзге ял чорында 11 нче сыйныф укучысы Мазитова Аэлина Китайда Халыкара дзюдо бәйгесендә беренче урын яулады. Алдагы ярышларында җиңүләр телибез.

Көзге ялларда 6а,3а сыйныфы укучылары Татарстан варислары берлеге программасында катнашып,1,2 урынны яуладылар. Җитәкчеләре: Нургалиева Ф.Р., Мозафарова Д.Я.

Хәрби-патриотк тәрбия максатыннан, шәһәребезнең истәлекле урыны булган “Мәңгелек ут” янында 9-11 нче сыйныф укучыларыннан торган команда сакта торды.

Мәгълүматны мәктәп спикеры Кәбирова Алинә туплады

**Безнең адрес: 423827, Яр Чаллы шәһәре, Яңа шәһәр, 52/36, 52 нче гомум белем бирү мәктәбе**

Телефон: (8552) 59-36-88

**Без Вебта: https://edu.tatar.ru/index.htm/sch52/page1067817.htm**